# Авылдашыбыз - Советлар Союзы Герое ГАБДУЛЛА Гарифуллин







Гарифуллин Габдулла Гарифулла улы 1924 елның 3 гыйнварында Татарстан Республикасының Балтач районы Яңгул авылында туа . 6 яшеннән ятим кала. Кызыл Армиягә чакырылганчы Донецк шәһәрендә ФЗӨда укый,  1941 елдан трактор заводында штукатурчы булып эшли. Шул елны туган колхозына эшкә кайта. Сугышка 1942 елның августында китә.






Сугышка киткәндә Габдуллага 18 яшь була. 1945 елның 23 апрелендә ул хезмәт иткән полк Берлин шәһәренә керә. Алдан ук, дошман камап алган шәһәргә кадарга дип, полк байрагын әзерләп куйган булалар. Полк командиры бу җаваплы эшне яшь сержант Габдуллага тапшыра. Баш очында сызгырып очкан пулялар астында, яшеренеп кенә килеп, егет ничек тә кварталның иң биек бинасына байракны беркетә ала.



**Габдулла Гарифуллин Берлинда барган урам сугышларында бер тәүлек эчендә дошманның 9 пулемётын, фауст патроннары белән коралланган 8 немецны һәм өч дистәләп автоматчыны юк итә.**









СССРның Югары Советы Президиумының 1946 ел 15 май Указы нигезендә Гарифуллин Габдулла Гарифулла улына Советлар Союзы Герое исеме бирелә.





**Мәктәпнең «Сугышчан дан» музеенда Советлар Союзы Герое Габдулла Гарифуллин истәлегенә багышланган зал эшли**










**Чепья
авылында
урнашкан
«Халыклар
дуслыгы»
музеенда да
авылдашыбыз
га
багышланган
вывеска бар.**












**Без үзебезнең авыл герое белән бик горурланабыз. Яңгул авылының бер урамы да аның исеме белән атала.**





Композитор, җырлар язучы Әнәс Сабиров һәм шагыйрь Мөбәрәк Галиев «Габдулла батыр турында җыр» иҗат иттеләр. Безнең районда бу җырны белмәгән кеше юктыр.



## *Габдулла батыр турында җыр.*

***М. Галиев сүзләре***

***Ә. Сабиров музыкасы***

***Ил өстендә кара өермәдәй***
***Ыргылганда фашист затлары,***
***Кем иңгә-иң күтәрелде,***
***Утлар кичте, җирен саклады-***

***Шул сафларда барды лачын сыман***
***Якташыбыз , тупчы Габдулла,***
***Үч алганчы соңгы илбасардан***
***Одерда һәм Эльба артында.***

***Полк үткән юллар хәвефле иде,***
***Мең гомергә торды адымы.***
***Тозак булды Волхов сазлыклары,***
***Өстән яуды металл яңгыры.***

***Ә шулай да беркем сыкранмады***
***Алга барды җиңү хакына.***
***Күккә очырды дошман танкларын***
***Ут яудырып батыр Габдулла.***

***Коелган кан эзсез югалмады,***
***Тар-мар килде дошман яулары***
***Таллинда да, Данциг, Берлинда да***
***Җилфердәде Җиңү байрагы.***

***Бәхет таңы атты Европада,***
***Тыныч тормыш туды халкыма.***
***Күкрәгенә Алтын Йолдыз тагып***
***Туган илгә кайтты Габдулла.***






Солдат, Габдулла Гарифуллинның дусты, рәссам Николай Антонович Наумов ясаган картинада герой оныгы белән












***Советлар Союзы Герое Габдулла Гарифулла улы Гарифуллин 2002 елның 1 августында вафат булды. Аның истәлек ташы куелган кабере кышын да, җәен дә чәчәктән өзелми***

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

